КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 август г.Казань № 797

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел,

26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче; 2021 ел, 30 октябрь,1030 нчы; 2022 ел, 30 май, 499 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче, 2022 ел, 15 июль, 683 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 6.4 пунктының 6.6.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6.4.4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе һәм әлеге үзәк филиаллары җитәкчеләренең база һәм хезмәт окладлары, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмасы исеме | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркеме | База оклады, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәт өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент күрсәткече | Хезмәт оклады, сум |
|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге | 1 | 38 000 | 1,0 | 38 000 |
| Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге филиаллары | 2 | 38 000 | 0,9 | 34 200». |

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин